# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**9 нчы декабрь 2024 ел** **№1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 5 декабрендә 14 сәгатьтә, 2024 елның 6 декабрендә 11 сәгатьтә , 2024 елның 6 декабрендә 14 сәгатьтә , 2024 елның 7 декабрендә 10 сәгатьтә, 2024 елның 9 декабрендә 10 сәгатьтә, 2024 елның 9 декабрендә 14 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Мөрәле авыл җирлеге Мөрәле авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсҗәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 300 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -159, бу 53 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 159 катнашучы тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен җыенның **0** катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең Мөрәле авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Мөрәле авыл җирлеге Мөрәле авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 700 (җиде йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Мөрәле авыл җирлеге Башлыгы Зиннәтуллин Р.Р.